**Татарстан Республикасы Азнакай районы Советы**
**дүртенче чакырылыш**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 291-35 «17» июль 2024 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башлыгы урынбасары Р.А. Галиевага карата юридик җаваплылык чараларын куллану турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт Вазыйфаларын һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш Комиссиясенең 2024 елның 08 июлендәге №ПР-140 номерлы карарыннан өземтә нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башлыгы урынбасары Р.А. Галиева тарафыннан 2023 елда керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган һәм тулы булмаган белешмәләр бирелгәнлеге билгеләнгән.

Татарстан Республикасы Азнакай районы Советы карар кабул итте:

1. “Коррупциягә каршы тору турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 статьясындагы 5 өлешендә, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы 7.1 өлешендә билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен, муниципаль вазыйфаны биләүче затка, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башлыгы урынбасары – Р.А. Галиевага кисәтү рәвешендә җаваплылык чараларын кулланырга.
2. Әлеге карарга карата Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.
3. Әлеге карарның күчермәсен биш эш көне эчендә Р.А. Галиевага язма рәвештә тапшырырга, яисә почта аша хәбәрнамә җибәреп җибәрергә, шулай ук Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә) җибәрергә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З.Шәйдуллин